| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 13.11.2020 | г.Казань | № 792 |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 4 декаберендә 7117 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм

социаль яклау министрлыгының 12.02.2020 № 89, 18.06.2020 № 435 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге 792 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының өченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының сигезенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.3 пунктының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы житешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

3 нче бүлектә:

3.4.1 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.2 пунктта:

беренче абзацта «әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «рәсми мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «рәсми мөрәҗәгать» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктта:

икенче абзацта «пунктчаларда» сүзләрен «пунктларда» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «министрга (министр урынбасарына) килештерү өчен» сүзләрен «министр урынбасарына килештерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары белән килештерелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү) министрга имзалау өчен җибәрелә.»;

сигезенче абзацта «10» санын «5» санына алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «министр (министр урынбасары) белән килештерелгән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына имза салу өчен җибәрелгән» сүзләрен «министр урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм министрга кул куюга җибәрелгән» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) имзалаганнан соң бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача, смс-хәбәр, электрон почта) бәяләмәнең әзерлеге турында хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләмә (бәяләмә бирүдән нигезле баш тарту) министр тарафыннан имзаланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.6.2 пунктның өченче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан

Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.2 пунктта:

өченче абзацта «министрга (министр урынбасарына) килештерү өчен» сүзләрен «министр урынбасарына килештерү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары белән килештерелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү) министрга имзалау өчен җибәрелә.»;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына имза салу өчен» сүзләрен «министрга имза салу өчен» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне) имзалаганнан соң бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача, смс-хәбәр, электрон почта) бәяләмәнең әзерлеге турында хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләмә (бәяләмә бирүдән нигезле баш тарту) министр тарафыннан имзаланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.8.4 пунктның өченче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Формасы

## Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән белдерү

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт сыйфатының ярашлылыгы турында бәяләмә бирүдән баш тарта:

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәвенә алу номеры)

күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең:

____________________________________________________________;

____________________________________________________________;

____________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең исеме)

Әлеге иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килми:

____________________________________________________________;

____________________________________________________________;

____________________________________________________________.

(критерияләргә туры килмәүләр күрсәтелә)

Министр ____________________ / ____________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)